Бүгенге санда:



**КАПИТАЛЬ РЕМОНТ КЫЗУ ЧОРЫНА КЕРӘ. 2 бит**


1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 20 март 2015 ел

№ 20 (10549)


**21 мартка һава торышы:** аз болытлы һава, җил көньяк- көнбатыштан 3-5 м/с; температура көндез +7°С, төнлә +1°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### ЧӘЧҮ АЛДЫННАН КИҢӘШМӘ

Кичә районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин җитәкчелегендә бер төркем агрономнар, “Россельхозцентр” белгечләре һәм идарә консультантлары Алексеевскида язгы кыр эшләре башлануга багышлап үткәрелгән зона семинар-киңәшмәсендә катнашып кайттылар. Киңәшмәдә сүз орлыкларның яңа сортлары, үсемлекләрне өстәмә тукландыру, уҗым культураларын карап торуның үзенчәлекләре һ.б.лар турында барган.

### БЕР СЫЕРДАН - 12 КИЛОГРАММ

Бүгенге көндә район хуҗалыкларында тәүлегенә 87 тоннадан артыграк сөт савыла, бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 9,7 тоннага артыграк. Бер сыерга тәүлеклек савым 12, 1 кг. тәшкил итә (республикада -13,4 кг). Район хуҗалыкларында барлыгы 7239 баш савым сыер исәпләнә.

### СЫНАУ УЗДЫЛАР

18 мартта районның 500 тугызынчы сыйныф укучысы сынау рәвешендә бердәм республика тестлаштыруы (ЕРТ) узды. Район мәгариф бүлегендә әйтүләренчә, ЕРТ нәтиҗәләре II яртыеллык билгеләрен чыгарганда исәпкә алыначак.

### ҺӨНӘРИ ОСТАЛЫК КОНКУРСЫНДА

“Ел тәрбиячесе-2015” республика конкурсының район турында җиңү яулаган номинантлар – “Бала үсеше үзәге”ннән Рушания Мусина һәм “Камыр Батыр”дан Азат Ягъфәров һөнәри осталыкларын зона турында яклаячаклар. Бәйге 20 мартта Алексеевскида узачак.

# Укучылар озын чирекне озата



Автор фотосы

УКУЧЫЛАР ИҢ ОЗЫН ЧИРЕКТӘН СОҢ ЯЛГА КИТӘ

**Район мәктәпләрендә 23 марттан язгы каникуллар старт ала. Укучылар өчен ял 9 көн дәвам итәчәк. Башка еллардан аермалы буларак, быел районның барлык 35 мәктәбе укучылары да язгы каникулга бер вакытта чыга.**

– Укучылар өчен иң озын чирек тәмамланды, – ди район мәгариф бүлеге җитәкчесенең тәрбия эшләре буенча урынбасары Эльмира Шагаева. – Гадәттәгечә, каникулларда мәктәпләрдә эш тукталмаячак. Барлык мәктәпләрдә түгәрәкләр эшләячәк, алар бездә 160 төр исәпләнә. Моннан тыш, спорт заллары ачык булачак. “Минем сәламәтлегем – минем кулларда” дип аталган спорт эстафеталары көтелә. Җиңүнең 70 еллыгына багышлап Кама аръягы һәм Нурлат тарихы төбәк музеена экскурсияләр оештырылачак. Бу чорда төрле фәннәр буенча сынау рәвешендә БДИлар уздыру да планга кертелгән. Аннан тимурлык эшләре дәвам итәчәк. Мәктәп укучылары ветераннарга, аларның толларына һәм тыл хезмәтчәннәренә төрле эшләрдә булышырга ниятләп тора. Моннан тыш, һәр мәктәп төрле темаларга КВНнар, төрле уеннар үткәрүне планлаштыра.

Әлбәттә инде, язгы каникуллар төрле конкурс-чараларга да бай булачак. Атна башыннан шәһәрнең 9нчы мәктәбе базасында “Балалар, техника, иҗат” дип аталган күргәзмә эшләячәк. Мәктәп драма түгәрәкләре өчен “Театр һәм балалар” дип аталган читтән торып уздырылучы конкурс көтелә. 25–29 мартта Казанның Спорт сарае күргәзмәләр комплексында узачак “Казанская чаша” халыкара ярминкәсендә Нурлатның яшь талантлары, Балалар иҗаты үзәгендә шөгыльләнүчеләр дә үз эшләрен тәкъдим итәчәк. Моннан тыш, яшь техниклар Алабугада узачак робототехника, Казанда судомоделирование буенча конкурсларга җыена.

Каникуллар алдыннан ЮХИДИ хезмәткәрләре дә укучылар белән әңгәмәләр үткәрә. “Яшь пассажирлар белән иминлек темасына әңгәмәләр алып барабыз һәм бу уңайдан белемнәрен дә тикшерәбез”, - ди инспекциянең пропаганда инспекторы Ринат Мөгайнетдинов. Гомумән, каникуллар алдыннан укучылар өчен янгынга каршы куркынычсызлык, юл хәрәкәте иминлеге, су буенда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә багышланган инструктажлар да узачак.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ЯЗГЫ ТАШУ

# Кисәтү артык булмый

**Чәршәмбе көнне районның санитар-эпидемиология комиссиясе язгы ташу чорына әзерлекне карады. Утырышны район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова алып барды.**

Бу чорда иң төп бурыч – инфекцион һәм инфекцион булмаган авыруларга юл куймау. Роспотребнадзорның Нурлат районы территориаль органы начальнигы урынбасары Лилия Субаева игътибар ителергә тиешле юнәлешләрне билгеләде. Эчә торган суга һәм канализациягә аеруча зур игътибар юнәлтергә кирәк, диде ул. Зур Чирмешән елгасыннан су алу станциясендәге фильтрлау блогын һәм канализация-чистарту корылмаларын зарарсызландыру чараларын һәм реагентларны җитәрлек күләмдә әзерләргә, су әзерләү һәм су чистарту, эчә торган суны зарарсызландыру технологиясен үтәргә кирәк, дип билгеләп үтте. “Безнең территориаль орган Зур Чирмешәннән алынучы суның сыйфатына микробиологик һәм санитар-химик, халык арасындагы йогышлы авыруларга мониторинг үткәреп тора, – диде Лилия Субаева. – Бүгенге көнгә районда эпидемиологик хәл тотрыклы, йогышлы авырулар теркәлмәгән”.

“Промочистка” җитәкчесе Ирек Шәйхетдинов язгы чорда су сыйфатын тотрыклы тоту буенча уздырылучы чаралар турында сөйләде. Андый чаралардан кварцлы ком фильтрлары ярдәмендә фильтрлау, икенчел зарарсызландыру, химик-бактериологик контрольне әйтергә була. “График нигезендә эчә торган суга лаборатор контроль алып барыла, урамнар һәм фатирлар буенча контроль нокталардан өстәмә пробалар алына. Кирәге чыкса, эчә торган су халыкка, балалар һәм дәвалау учреждениеләренә артезиан скважиналарыннан транспорт белән китереләчәк”, – диде ул.

Утырышта үләт базлары, биотермик чоңгыллар аерым мәсьәлә буларак каралды. Районның баш ветеринария табибы Василий Лысов әйтүенчә, алар су басу зонасына керми икән.

Комиссия утырышына йомгакны Нурлат гарнизоны начальнигы Илһам Курамшин ясады. Ул әлегә һава торышы көйле торганда, ташуга каршы барлык чараларны да алдан күреп куярга кирәклеген ассызыклады.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

**1 АПРЕЛЬГӘ КАДӘР РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ЭЛЕККЕГЕ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП КАЛЫРГА ӨЛГЕРЕГЕЗ!**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ДЕПУТАТ ХОЗУРЫНДА

## Мөрәҗәгатьләр игътибарсыз калмаячак




ДЕПУТАТКА КИЛҮЧЕЛӘРНЕ ТӨРЛЕ ХАРАКТЕРДАГЫ СОРАУЛАР БОРЧЫЙ.

**Һәр айның өченче сишәмбесендә ТР Дәүләт Советы депутаты Рәис Сөләйманов нурлатлыларны кабул итә.**

Бу айдагы кабул итү 17 мартта Мәдәният сараенда "Бердәм Россия" сәяси партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе җәмәгать кабул итүе бүлмәсендә үтте. Депутатка бу көнне шәхси сораулар белән 11 кеше мөрәҗәгать итте.

Гадәттә, депутат кабул итүенә күпләр үз проблемалары белән төрле инстанцияләргә йөреп аргач, чыгу юлын таба алмаганда мөрәҗәгать итә. Бу юлы да күпләр депутаттан реаль ярдәм буласына ышанып килгән. Әнә, авыр тормыш хәлендә калган нурлатлы Дәүләт Советы депутатына эшкә урнашуда булышуын сорап мөрәҗәгать итте. Бухгалтер-экономист һөнәренә ия яшь белгеч төрле оешма-предприятиеләргә йөреп эш эзләп караган инде, әмма, үзе әйтүенчә, файдасыз, бар җирдә дә эш тәҗрибәсе кирәк. Бу көнне мөрәҗәгать итүчеләр арасында шулай ук йорт төзү өчен участок алу, пай җирләрен рәсмиләштерү, мирас кабул итеп алуда ярдәм һәм башка шундый характердагы шәхси сораулар белән килүчеләр дә бар иде. Ә менә Түбән Чаллыдан Иван Осипов тулаем авыл халкының үтенече белән килгән.

- Безнең авыл янында әле 1914 елда ук казылган күл бар иде, - ди ул. – Бик чиста сулы, балыклы күлебезгә ел саен хәтта торналар төшә торган иде. Әмма менә инде 7 ел буена ясалма күлебез сусыз, аны чистартасы иде, - дип мөрәҗәгать итте ул Рәис Сөләймановка.

Депутат исә мөрәҗәгатьне җентекләп тыңлаганнан соң, күлне чистарттыруны республикада гамәлдә булган программаларның берсенә 2016 елга кертергә тырышачакларын әйтте. Иван Сергеевичның тагы бер – көтүлекләргә кагылышлы үтенечен дә депутат үзенең шәхси контроленә алды.

- Бүген нурлатлыларны төрле сораулар борчый. Аларның кайберләрен район җитәкчелеге, төрле инстанцияләр белән хәл итәргә туры киләчәк. Әмма мөрәҗәгатьләрнең берсе дә игътибарсыз калмаячак, - диде Дәүләт Советы депутаты кабул итүдән соң.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

КАПРЕМОНТ-2015

## Халык рәхмәте – иң яхшы бәя

**Быел Нурлатта капиталь ремонт программасы буенча 15 объектта эшләр алып барыла. Шуларның икесендә "Домстрой" җәмгыяте мәшгуль.**

Бу төзелеш компаниясе күптән инде үзен чын һөнәрмән итеп танытты. Мисал өчен, узган ел "Домстрой" Түбән Чаллы мәктәбен, Шашин урамындагы 27нче йортны ремонтлады, моннан тыш, әлеге оешма төзүчеләре "Татнефть" бүлеп биргән средстволарга Гагарин урамындагы 26нчы йортның түбәсен алыштырды. Шулай ук Хәммәдиев урамындагы 2нче йортның йомшак түбәсе урынына ике кыеклыны ясадылар, аны профнастил белән дә тышладылар.

– Бу күчмә объект, һәм биредә быел да эшләр дәвам итәчәк, – ди "Домстрой" директоры Михаил Митин.

Биредә салкын су системасын, канализацияне алыштырганнар инде. Эшләр зур күләмдә булуга да карамастан, 33 фатирлы бу йортта алар иң кыска срокларда башкарылган – өч атна эчендә эшләп чыкканнар. Иске торбаларны салдырганнар, алар урынына полипропиленны сузганнар, подвалда разводка һәм беренче ябу кранына, ягъни фатирлардагы су исәплэгечләренә кадәрге стояк алыштырылган. Канализация системасында

вал өлешендә беренче коега кадәр ПВХ торбалар сузылган, стояклар алыштырылган, ә фатирларга яңа унитазлар куйганнар. Бу вакытка подъездда электр челтәрләре буенча инженерлык эшләре дә төгәлләнгән: керү кабелен һәм фатирларга кадәрге электр үткәргечләрен алыштырганнар. Тулаем алганда, электр хуҗалыгына 420 метрлап үткәргеч киткән, яңа щитлар, автоматик яктылык диодлы лампалар да куйганнар.

– Берничә электр исәплэгече фатир эчендә иде, хәзер барысын да подъездга чыгардык, – диде предприятиенең прорабы Геннадий Васильев, аның булдыклы кулы астында объектларда 9-10ар кеше мәшгуль. "Намуслы эшләделәр", – диләр алар турында әлеге йортта яшәүчеләр.

– Алар ял көннәрендә дә биредә булдылар, безгә мәшәкатьләр дә тудырмадылар, – дип сөенечләрен уртаклаша Хәммәдиев урамының 2нче йортында яшәүче Татьяна Григорьева. – Безнең фикерләргә дә колак салдылар. Җылылык системасын алыштырыр чират җиткәч тә, алар бу эшне ыгы-зыгысыз гына, яхшы иттереп башкарырлар дип уйлыйм.

Түбән Чаллы мәктәбендә дә подрядчылар турында җылы сүзләр генә ишеттек.

– "Домстрой" эшчеләрен яхшы сүзләр белән генә искә алабыз,




КИЧӘ ГЫЙМАТДИНОВ УР., 47нче ЙОРТТА ИШЕКЛӘР КУЯ БАШЛАДЫЛАР

– ди башлангыч мәктәп мөдире Алевтина Шартынова. – Моңа кадәр кышын тәрәзәләр ачкаларыбыз юк иде әле. Безгә бик уңай шартлар тудырдылар. Түбәне, тәрәзәләрне, ишекләрне, электр хуҗалыгын, керү ишекләрен алыштырдылар, моннан тыш, линолеум җәйделәр, стеналарга заманча стеклообойлар ябыштырдылар. Гардероб бүлмәсе төзеделәр – кирпечтән өеп, ишекләр куйдылар, актлар залын тулысынча яңарттылар. Санузелыбыз юк иде – монысы да хәл ителде, вытяжка белән дә проблема юк хәзер.

Бу көннәрдә "домстройныкылар" Гыйматдинов урамындагы 47нче йортта эшли. Биредә түбәне алыштырганнар – иске шиферны сүтеп, профкалай япканнар. Подъезд ишекләре түбәсенә козыреклар куелган. Кичә ишек-тәрәзәләрне алыштыруга керештеләр, аннан подъездларгы электрикага тотыначаклар. Биредә дә, үзләренә тапшырылган башка объектлардагы кебек үк, "Домстрой" эшчеләре хезмәтләре заяга китмәсен өчен тырышачак. Һәм бу хакта исә әлеге йортларда яшәүчеләрнең бәяләреннән чыгып фикер йөртергә була.

Сирень **СӘМӘРХАНОВА**

### ХӘБӘРЛӘР

## РЕЙДЛАРГА УЧАСТКОВЫЙЛАР ДА КИРӘК

**Сишәмбе көнне район Советында хезмәтләр күрсәтүчеләр белән очрашу булды.**

Бу сөйләшү февральдә коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең җыелуы мәсьәләсен хәл итү өчен уздырылды. Очрашуга район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова җитәкчелек итте.

Биредә Бердәм исәп-хисап үзәге, суд приставлары бүлеге, "Татэнергосбыт" һәм башка службалар җитәкчеләренең фикерләре тыңланды. "Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне нәтиҗәле җыю өчен рейдларда идарәче оешмаларның, күпфатирлы йортлар советлары вәкилләренең һәм йорт буенча җаваплыларның, "Татэнергосбыт", электр челтәрләре вәкилләренең катнашуы кирәк, – диде шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин. – Фатирларга керер өчен участковыйлар да булырга тиеш. Алты йортта февраль өчен электр энергиясенә ОДН барлыгы ачыкланды. Шуңа да бердәм исәп-хисап үзәгенә бу йортларны рейдлар графигына кертү зарур".

Очрашуда йортлар буенча җаваплылар да катнашты. Алар үз йортларында яшәүчеләрне борчыган сорауларга җаваплар алдылар.

Сирень **СӘМӘРХАНОВА**

## МИНИСТР КАБУЛ ИТТЕ

**17 мартта ТРның хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова видеорежимда гражданнарны кабул итте. Бу көнне министрга 7 нурлатлы үз гозерен җиткергән.**

– Министрга социаль хезмәтләргә яңа тарифлар, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына социаль ярдәм, мәшгульлек һәм балалар бакчаларына компенсацияләр алуга бәйле сораулар бирелде. Барлык мөрәҗәгать итүчеләр министрның консультацияләрен алдылар, - диде районның социаль яклау идарәсе начальнигы Ирина Афанасьева.

## "IT-ЧЕМПИОН" БӘЙГЕСЕ БАШЛАНДЫ

**18 марттан район мәктәпләрендә "IT-чемпион" III республика конкурсы старт алды.**

"Быел конкурс "Иң актив укучы" һәм "Иң актив мәктәп" номинацияләрендә узачак. Беренче номинация ике этапта: 18 марттан 31 июльгәчә һәм 1 августтан 30 ноябрьгәчә үтәчәк. Икенче номинация бер этапта: 18 марттан 30 ноябрьгә кадәр барачак. "Иң актив укучы" номинациясендә өч җиңүче планшет компьютерлары белән бүләкләнсә, муниципалитетның иң актив мәктәбе интерактив җиһазга ия булачак", – ди мәгариф идарәсе методисты Рузилә Гатина. Шунысын да әйтергә кирәк, 2013 елда әлеге конкурста районның 11 укучысы планшетка, ә 2014 елда 6 бала ноутбукка ия булган иде. Узган ел мәгариф учреждениеләре арасында Елаур урта мәктәбе интерактив җиһаз белән бүләкләнде.

Зилия **ӘКСАНОВА**

## ТУКАЙГА БАГЫШЛАП

**Габдулла Тукайның туган көненә җирлекара үзәк китапханә нурлатлылар арасында интернет-викторина игълан итә.**

20 марттан 20 апрельгәчә барачак викторинада шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына кагылышлы 20 сорауга җавап бирәсе. Викторинаның нигезләмәсе һәм биремнәре белән китапханә сайтында танышырга мөмкин. Нәтиҗәләр 26 апрельдә Татарстанда Туган тел көнендә билгеле булачак.

Маргарита **ЛИТТА**

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

# Һәр солдатның үз язмышы

**Иске Әлмәт авыл җирлегенә караган авыллардан Бөек Ватан сугышына 506 кеше киткән. Шуларның 274е һәлак булган, 232се әйләнеп кайткан. Бүген аларның да нибары 5се генә исән. Ике ветеран Иске Әлмәт авылында яшәсә, калганнары читтә. Бүгенге көндә җирлектә 36 тыл хезмәтчәне яши.**

Иске Әлмәт авылында яшәүче **Рәшит Гатинга** 23 апрельдә 90 яшь тула. Ул сугышка 1943 елның 10 гыйнварында алына. Башта II– III Балтыйк буе фронтларының 16нчы Кызыл Байраклы танк бригадасында, аннан Польская дивизиясендә, 1945 елдан V гвардия корпусының 10нчы бригадасында сугыша. Сугыш тәмамлануга 20 көн калгач, авыр яраланып, госпитальләрдә дәвалана, 1945 елның 20 июлендә авылга кайта. Яңа Әлмәт кызы Разияга өйләнеп, өй тулы балалар үстерәләр, олы тормыш юлына бастыралар. Тыныч тормышта озак еллар колхозда хисапчы, баш хисапчы һәм ревизия комиссиясе рәисе вазифаларын башкарды ул. Сугыштагы батырлыклары өчен ветеран I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән.

Тагы бер ветеран – **Касыйм Морадыймовка** 92 яшь. Сугышка ул 1942 елның 17 апрелендә алына. Волхов фронтындагы сугышларда катнаша. 1943 елда яраланып, сержант дәрәҗәсендә туган авылына кайта. Аннан Яңа Әлмәт МТСы оешкач, тракторчы, комплекс бригадирының техника буенча ярдәмчесе, бригадир һәм электрик булып эшләп лаеклы ялга чыга. Орден һәм медальләр, хәрби билгеләргә лаек булган ул. Тормыш иптәше Асия апа вафат булгач, ул авылда хәзер ялгызы яши.

**Моксин Мусин** 1924 елның 3 июлендә Колбай Мораса авылында туа. Әтисе 1927 елда Нариман поселогын оештыргач, шунда яши. Ә 1942 елның июль аенда сугышка китә. I Белоруссия фронты составында авыр миномет артиллериясенең "Катюша" тибындагы полкында хезмәт итә. Яралана, әмма полкта кала. Армиядән 1947 елда гына әйләнеп кайта. Тимерче булып эшли, 1955 елда Халидәгә өйләнеп, балалар үстерәләр. Быел аларның бергә гомер итүләренә 60 ел була.

**Николай Суслов** 1925 елның 15 декабрендә Иске Рус Әлмәте авылында дөньяга килә. Аннан гаилә Мамык авылына күченә. 1943 елда сугышка алынган Николай Степанович Монголиядә дә хезмәт итә. Биредә алар сугыш барган якка атлар озаталар. Шул ук елны ул II Украина фронтында артиллерия орудиясе командиры булып хезмәт итә башлый. Украина, Румыния, Венгрияне азат итүдә катнашып, Җиңү бәйрәмен Будапешт шәһәрендә каршы ала. Сугыш тәмамлангач, 1950 елга кадәр Харьков шәһәрендә хезмәт итә. Мамык авылы кызы Зояга өйләнеп, 5 бала тәрбиялиләр. Төрнәс совхозында, аннан районның терлекчелек продуктлары җитештерү буенча баш инспекторы булып эшли.

Яңа Әлмәт авылында туып үскән **Вәгыйзь Гиняев** 1943 елның азагында Кадыйр Фәхретдинов белән бергә Бөек Ватан сугышына алына. Кадыйр Шәйхетдин улы 1944 елның азагында Венгрияне азат иткәндә һәлак була. Ә Вәгыйзь бернічә мәртәбә яраланып, сугыш тәмамлангач та армия сафларында хезмәт итә, полковник дәрәҗәсенә ирешеп, бүгенге көндә тормыш иптәше белән Казанда яши. Бик күп орден һәм медальләр белән бүләкләнгән.

**Зәкия Туишева** 1919 елда Куйбышев өлкәсендә туып, гаиләләре белән 1921 елда Яңа Әлмәт авылына күченеп килә. Аннан 1936 елда Казанга китә. ФЗӨ мәктәбендә укый, театр студиясендә эшли. Сугыш башлангач үзе теләп армиягә китә. Анда концерт труппалары белән йөри, шәфкать туташы була. Калугадан алып Берлин, Прага шәһәрләренә кадәр җитә. Сугыштан соң да гомерен театрга багышлый. Республиканың атказанган һәм халык артисты Зәкия Туишева – бүген Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданины.

Венгрия вакыйгаларында да безнең авыл җирлегеннән 3 солдат катнаша. Бүген аларның берсе – **Сәмигулла Әхмәтшин** гына исән. Заманында XXI партсъезд колхозында тракторчы булып эшләгән авылдашыбыз бүген балалары янында Яр Чаллы шәһәрендә яши.

Дәһшәтле әфган вакыйгаларында да 7 егет үз бурычын үтәп кайтты. Шуларның бары берсе – **Александр Софронов** кына авылда яши. Чечня бәрелешләрендә катнашкан 8 егетнең өчесе – **Фәнис Гарифуллин, Рәис Хамматов** һәм **Илшат Минабетдинов** авылда төпләнеп калдылар.

Авыл халкы барлык ветераннарны, сугышчы-интернационалистларны һәм яшь солдатларны һәрчак тирән ихтирам белән истә тотсын иде.

**Җәүдәт ХӘЙРУЛЛИН, Иске Әлмәт авылы**



АГРИППИНА КАДЯШЕВАНЫ РАЙОН БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫ ФЛЮРА НОГМАНОВА КОТЛЫЙ.

# Хезмәттә узган гомер

**Егоркино авылында яшәүче тыл хезмәтчәне Агриппина Кадяшевага 90 яшьлек юбилее уңаеннан РФ Президенты Владимир Путин һәм район җитәкчелегенең котлавы ирештерелде.**

Район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова тыл хезмәтчәненә Җиңүнең 70 еллыгына багышланган юбилей медален дә ташырды. Бу көнне юбилярны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Әлфия Галәветдинова, Егоркино авыл җирлеге башлыгы Валентина Яковлева да тәбрикләде.

Агриппина Кадяшева бар гомерен туган авылына багышлый. Яшьтәшләре кебек үк мәктәпнең башлангыч сыйныфын тәмамлау белән хуҗалыкка эшкә чыга. Ә сугыш елларында ул торф чыгаруда була. Сугыш тәмамлангач авылга кайтып төпләнә, төрле хуҗалык эшләрендә мәшгуль була. "Гомере буе таза тормыш белән яшәде апабыз. Бакча утыртты, терлек-туарын асрады. Бертуганы Ольга белән яңа йортка кадәр салып чыкты ул. Әле дә хәтеремдә, аның аяклы "Зингер" тегү машинасы, туку станогы бар иде. Кулыннан килмәгән эше юк иде бит. 87 яшькә кадәр берүзе яшәде, менә соңгы өч елда үзебезнең гаиләгә алып кайттык апабызны", - ди бертуганының улы Павел.

***

*Бөек Җиңүнең 70 еллыгы хөрмәтенә юбилей медальләре тапшыру тантанасы тимер юлчылар бистәсендә, 8нче урта мәктәптә дә узды: бу көнне әлеге зур бүләкләрне 91 кеше алды.*

*Район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова Бөек Ватан сугышы ветераны Борһан Галәветдинов, блокадачы Игорь Ивлев һәм ветераннар, тыл хезмәтчәннәре адресына котлау теләкләрен җиткерде. Юбилей медальләре тапшыруга багышланган тантанага мәктәп укучылары концерт программасы да әзерләгән иде. Тантаналарның чираттагысы шәһәрнең 4нче мәктәбендә узды. Анда барлыгы 38 өлкән яшьтәге кешегә юбилей медальләре тапшырылды.*

**Зилия ӘКСАНОВА**

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

# Белемне арттырып тору кирәк



УКУЛАР КҮП ТЕМАЛАР БУЕНЧА БЕЛЕМНӘРНЕ АРТТЫРЫРГА МӨМКИНЛЕК БИРДЕ.

**Сишәмбе көнне 40тан артык авыл хуҗалыгы белгече аграр техникум базасында уку узды.**

Татар агробизнес кадрларын кабаттан әзерләү институтында авыл хуҗалыгы белгечләре даими рәвештә белемнәрен күтәреп торалар, уку йорты белгечләре районнарга чыгып та куима укулар оештыра. Бу юлы институтның уку эшләре буенча проректоры, профессор Владимир Фомин, доцент, ветеринария фәннәре докторы Рафаэль Исхаков, доцент Айдар Нигъмәтҗанов районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе консультантларын, хуҗалык агрономнары, зооветеринария белгечләре, инженерларын җыйды.

- Мондый укулар ай дәвамында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы инициативасы буенча республиканың барлык районнарында да уза. Бүген исә дәресләрне "түгәрәк өстәл" формасында үткәрәбез. Чөнки мондый дәресләрдә сөйләшүне белгечләрне күбрәк кызыксындырган темалар буенча алып барырга мөмкин, - ди Рафаэль Шәрифович.

Бу көнне исә сөйләшү нигездә үсемлекчелек һәм терлекчелектә сакчыл производство технологияләре, агросәнәгать комплексының Бөтендөнья сәүдә оешмасы һәм икътисадый санкцияләр шартларында нәтиҗәлелеген арттыру, азык әзерләүдә прогрессив алымнар һәм башка көнүзәк темалар буенча барды. Белгечләр дә укуларның язгы чәчү һәм терлекләрне җәйләү чорына күчерер алдыннан бик кирәкле һәм урынлы булуын, аннан үзләре өчен күп яңалыклар алуларын билгеләп үттеләр.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

КЕШЕ ҺӘМ ЗАКОН

# Ак халаттагы тап

**Нурлат районы суды табиб-хирургны ялган документлар ясау һәм ришвәт алуда гаепләп, 2 елга сынау срогы белән шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм итте һәм дәүләткә 112000 сум күләмендә штраф түләргә дигән карар чыгарды.**

- Суд утырышында хезмәткә яраклы булмау турында белешмә бирергә хокукы булган табиб-хирург М.ның гражданин А.дан ришвәт алу максаты белән эшкә яраксызлык белешмәсенә имгәнү турында ялган мәгълүматлар кертүе расланды, - ди ТР Нурлат районы суды судья ярдәмчесе Алия Гыйльметдинова. – Ул шулай итеп А.ны ике атнага эштән азат иткән. 14 көнлек больничный өчен 2800 сум күләмендә ришвәт алганнан соң, табиб эшкә яраксызлык турындагы белешмәне гражданин А.га бирә. Судка тапшырылган дәлилләрне берләштереп караганнан соң, суд гражданка М.ны Россия Федерациясе Җинаятьләр кодексының 292нче маддәсе 1нче өлеше (хезмәт урыныннан файдаланып ялган документлар ясау) һәм 290нчы маддәсенең 3нче өлеше (ришвәт алу) буенча гаепле дип таба. Апелляция инстанциясе суды Нурлат районы судының карарын үзгәрешсез калдыра, ә хөкем ителүченең дәгъвасын кире кага.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА




## УКУЧЫЛАР ТОРМЫШЫ

# ИГЕЛЕККӘ УРЫН БАР

**Узган атна дәвамында шәһәрнең 1нче мәктәбендә Язгы игелек атналыгы кысаларында төрле чаралар үткән.**

Нәрсә ул игелек? Җирдә нәрсә күбрәк: игелекме, әллә начарлыкмы? Игелеклеме мин?

Атна дәвамында сыйныф сәгатьләрендә һәм чараларда әнә шул һәм башка бик күп сорауларга җаваплар эзләгәннәр мәктәп укучылары. Һәм игелеккә кайда да урын бар дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Әнә, 1нче сыйныф укучылары сыйныф сәгатьләрендә игелек кылуның әти-әниләре, дуслары, күршеләренә булышудан башлануын белгәннәр, үзләренең игелекле эшләрен искә төшереп, алардан Игелек агачы да булдырганнар. Ә 2нче сыйныфлар үзләренең игелекле теләкләрен нурларга язып, тулы бер кояш ясаган. 5нче А сыйныфы укучылары тәкъдим иткән "Һәр кешегә елмаю бүләк ит" акциясе кысаларындагы флеш-моб та мәктәп укучыларын җәлеп иткән. Игелек төшенчәсенең исә мәгънәсе киңкырлы. 5нче Влар, мәсәлән, аны мәктәп ишегалдындагы уен мәйданчыгын чүп-чардан чистартып экологик акция үткәрүдә күргән. 7Б сыйныф укучылары да игелек турында сөйләшеп кенә калмаганнар, бергәләшеп хезмәт ветераны, тыл хезмәтчәне Зинаида Михайловна Хорошеваның өенә барып ярдәм итәргә карар кылганнар. Егетләр ишегалдындагы карны көрәгәннәр, ә кызлар өйдә савыт-саба юганнар, тузаннар сөрткәннәр. Кыскасы, игелек атнасында мәктәпнең бер генә сыйныфы да игелекле эшләрдән читтә калмаган.

# УҢЫШЛЫ АТНА

**Узган атна азагында Балалар сәнгать мәктәбе укучылары ике конкурста уңышлы чыгыш ясап кайттылар.**

Яр Чаллыда үткән "Тат-ARS-Тан" балалар һәм үсмерләр иҗаты республика конкурсында Гүзәл Яруллина (домра) II дәрәҗә, Наталья Кириллова (домра) һәм Гүзәл Яруллина белән Арина Евдокимова (фортепиано)ның ансамбле – III дәрәҗә лауреат исемнәренә лаек булды. Шул ук конкурстан Булат Мөбарәкшин (домра) I дәрәҗә, домрачылар ансамбле III дәрәҗә дипломант исемнәре алып кайтты. Укытучылары Валентина Бурганова белән концертмейстерлар Валентина Бадина һәм Рузалия Гайнанованың хезмәте югары һөнәрмәнлек өчен дипломы белән билгеләп үтелде.

Ульян шәһәрендә үткән "Волга в сердце впадает мое" Халыкара конкурс-фестивалендә Юлия Трубкина (виолончель, укытучысы Светлана Гнусарева), Гөлназ Гайнетдинова (скрипка, Ольга Икрамова) – I, ә Риназ Әхмәтҗанов (гитара, Сергей Рамазанов, концертмейстерлары – Әлфия Крепышева) II дәрәҗә дипломант булдылар.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА** әзерләде

## СПОРТ

### НЕФТЬЧЕЛӘР СЫНАТМЫЙ

**Узган якшәмбе көнне Әлмәт районындагы "ЯН" тау чаңгысы комплексында "Татнефть" спартакиадасының тау чаңгысы буенча ярышлары үтте. Анда 36 команда катнашты, алар арасында "Нурлатнефть" спортчылары да бар иде.**

Һәр команда өч спортчыдан торды (ике ир-ат һәм бер хатын-кыз). Нурлат нефтьчеләре ярышларда уңышлы чыгыш ясадылар. Мисал өчен, ППН операторы Дмитрий Белов тау чаңгысы слаломында I урын яулады. ППН лаборанты Резедә Ибраһимова шул ук төрдә III булды. Нәтиҗәдә, команда зачетында "Нурлатнефть" спортчылары бишенче урынга чыкты. Шул ук көнне нурлатлылар, шул исәптән "Нурлатнефть" вәкилләре дә Бөтенроссия Сембер чаңгы марафонында катнашып кайттылар. Ул Ульян шәһәрендә узды. Төп төркемдә 50 километрлы дистанциядә "Нурлатнефть" идарәсенең М.Хуҗин исемендәге спорт комплексы тренеры Александр Элекин II урын алды, 40-50 яшьлекләр арасында нурлатлы Андрей Сиражетдинов III килде. Өлкәнрәк чаңгычылар белән беррәттән, Нурлатның 1нче мәктәп укучысы Айдар Әндаров та матур нәтиҗәгә иреште: ул 30 чакрымлы дистанциядә III урын алды.

### КҮРШЕДӘГЕ ЧИРАТТАГЫ ҖИҢҮЛӘР

**14 мартта Самара өлкәсенең Шентала районында "Шентала чаңгы юллары" ярышлары үтте.**

– Әлеге ярышлар ел саен уздырыла, ул Самара өлкәсенең массакүләм чаңгы узышлары статусын йөртә, – ди ДЮСШ тренеры Иван Белов. – Анда безнең район чаңгычылары да еш катнаша. Быел да күпсанлы көчле спортчылар арасында матур нәтиҗәләр күрсәтә алдык.

"Шентала чаңгы юллары"ннан Радик Ибраһимов, Виталий Герасимов, Вячеслав Янилкин, Петр Казаков җиңүче исемнәре яулап кайттылар.

### БЕР ДИСТӘ МЕДАЛЬ ЯУЛАДЫЛАР

**14-15 мартта Бөгелмә шәһәрендә кикбоксинг буенча тренерлар М.Әхмәтшин һәм Ф.Хәйруллин истәлекләренә республика турниры үтте. Анда Нурлат балалар-үсмерләр спорт мәктәбе шәкертләре дә уңышлы чыгыш ясап кайттылар.**

"Турнирга унөч спортчы алып барган идек, шуларның унысы призлы урыннар яулады", – дип шатлыкларын уртаклашты ДЮСШ тренеры Евгений Казаев. Шул рәвешле, Ильяс Хөснетдинов, Данил Морозов, Булат Шәйдуллин, Булат Шәфыйков һәм Илназ Гыйләҗев җиңүче исемнәре яуладылар. Марат Баймурзин, Данил Бикинеев, Рөстәм Сөләйманов һәм Булат Яруллин – II, Тимур Шәфыйков III урыннар белән кайттылар.

Сирень **СӘМӘРХАНОВА**, Илназ **МӨБАРӘКШИН**

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

ГАДӘТТӘН ТЫШ

## САК БУЛЫГЫЗ: МОШЕННИКЛАР!

**Яз башы Нурлаттагы бер таксист өчен күңелсез хәлдән башланган. Аңа шәһәрдәге бер предприятиедән пицца алырга һәм адрес буенча китерергә, дигән заказ керә. Юл уңаенда заказчы тагы бер шалтырата һәм берочтан телефонына 500 сум акча салуны да сорый. Ә урынга килеп җиткәч, таксист моның мошенниклар эше икәнлегенә төшенә.**

